СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**

**Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**30 октябрь 2023 ел** **№10**

**Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Печмәнтау авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Ташкичү авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Печмәнтау авылында Печмәнтау авылы, Җиңү урамы, 22 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 15 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ашытбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидларга, 75 яшьтән узган гражданнарга, көндезге формада белем алучы студентларга 250 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;

- рөхсәтсез чүплекне рекультивацияләү;

- җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл полотносы нигезләү һәм каплау: Җиңү урамы;

- зиратны тоту өчен җиһазлар сатып алу (бензопила – 1 данә)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

3. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Печмәнтау авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Печмәнтау авылы, Җиңү урамы, 22 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы

Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Хабибуллин